**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**

422750, село Большая Атня,
улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОНЫНЫҢ**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы,
Совет урамы,38нче йорт

Тел./факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

14 апрель 2020 ел. № 135

Әтнә районы Башкарма комитетының 20.02.2018 ел, № 40 карары белән расланган “Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына” үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексын (2019 елның 27 декабрендәге үзгәрешләр белән), 29.12.2004 елдагы 190-ФЗ номерлы РФ Кодексын тормышка ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 02.11.2010 елның 880 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә Әтнә район башкарма комитеты карар бирә:

1. Әтнә район башкарма комитетының 20.02.2018 ел, № 40 номерлы “Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау” турындагы карары белән расланган, “Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына” кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында, шулай ук Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесе урынбасары М.Л. Халиковка йөкләргә.

Җитәкче А.Ф.Каюмов

Кушымта
Әтнә районы
башкарма комитетының
14.04.2020 ел, 135нче номерлы
карарына

Әтнә район башкарма комитетының 20.02.2018 ел, № 40 номерлы, “Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау” турындагы карары белән расланган, “Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына” кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1. 2.4 пункттагы "гаризаны теркәгәннән соң 17 көн эчендә” дигән җөмләне түбәндәге эчтәлекле җөмлә белән алыштырырга «гаризаны теркәгәннән соң 14 көн эчендә".